**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 1 июлендәге 2753 номерлы карары**

**«“Ял” исемле балаларны һәм яшүсмерләрне сәламәтләндерүне, ял иттерүне һәм эш белән тәэмин итүне оештыру буенча шәһәр үзәге» Казан шәһәре яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесенең җәйге профильле сменаларында катнашу өчен кандидатлар сайлап алу тәртибе турында**

Талантлы балаларны интеллектуаль, фәнни, иҗади, спорт һәм иҗтимагый эшчәнлектә ирешкән уңышлары өчен бүләкләү максатыннан **карар бирәм**:

1. «“Ял” шәһәр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең җәйге профильле сменаларында катнашу өчен кандидатларны сайлап алу тәртибе турында нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

2. Казан шәһәре мәгариф учреждениеләре укучыларының «“Ял” шәһәр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең җәйге профильле сменаларында катнашу квотасын расларга (2 нче кушымта).

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә (И.А.Ризванов):

3.1. «“Ял” шәһәр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең җәйге профильле сменаларында катнашу өчен кандидатларны сайлап алу тәртибе турында мәгълүматны Казан шәһәре муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләренең мәгълүмат стендларында һәм сайтларында урнаштырырга;

3.2. «“Ял” шәһәр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең җәйге профильле сменаларында катнашу өчен кандидатлар сайлап алу тәртибен ата-аналарга һәм педагогларга ирештерергә;

3.3. кандидатларны «“Ял” шәһәр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең җәйге профильле сменаларында катнашу өчен кандидатлар сайлап алу тәртибе турындагы Нигезләмәдә күрсәтелгән критерийлар нигезендә сайлап алырга;

3.4. җәйге профильле сменаларда катнашу өчен сайлап алынган балалар исемлекләрен «Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре буенча комитеты» муниципаль казна учреждениесенә тапшырырга.

4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре буенча комитетына (А.Р.Заһидуллина):

4.1. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе тарафыннан тапшырылган исемлекләр нигезендә җәйге профильле сменаларда катнашучыларның гомуми исемлеген төзергә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан гамәлгә керә һәм һәм 2024 елның 20 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарны, билгеләнә торган кызыл линияләрнең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән тыш (хезмәттә файдалану өчен материаллар), «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

1 нче кушымта
Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 1 июлендәге
2753 номерлы карары белән
расланган

**«“Ял” шәһәр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең җәйге профильле сменаларында катнашу өчен кандидатларны сайлап алу тәртибе турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә «“Ял” исемле балаларны һәм яшүсмерләрне сәламәтләндерүне, ял иттерүне һәм эш белән тәэмин итүне оештыру буенча шәһәр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең җәйге профильле сменаларында (алга таба – җәйге профильле сменалар) катнашу өчен кандидатларны сайлап алу тәртибен һәм шартларын билгели.

1.2. Җәйге профильле сменаларда катнашу өчен кандидатлар сайлап алу талантлы балаларны укуда, интеллектуаль, фәнни, иҗади, спорт һәм иҗтимагый эшчәнлектә ирешкән уңышлары өчен бүләкләү максатыннан үткәрелә.

1.3. Җәйге профильле сменаларны «“Ял” шәһәр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе (алга таба – «Ял» үзәге) оештыра.

1.4. Җәйге профильле сменаларда катнашу өчен кандидатларны сайлап алу Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы Казан шәһәре муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләре (алга таба – мәктәпләр) тарафыннан Казан шәһәре Башкарма комитеты карары белән расланган квоталар нигезендә башкарыла.

## II. Кандидатларны сайлап алу тәртибе

2.1. Җәйге профильле сменаларда мәктәп укучылары катнаша.

2.2. Катнашучылар составы өлгереш буенча балары уртача булган 7 яшьтән 17 яшькә кадәр сәләтле, иҗади балалар арасыннан, мәктәп, әлеге мәктәп урнашкан Казан шәһәре районы тормышында, шулай ук сайлап алу критерийлары нигезендә Казан шәһәре тормышында актив катнашучы балалардан төзелә (нигезләмәгә 1 нче кушымта).

2.3. Укучы портфолиосы беркетелгән укучының ата-анасы гаризасы конкурста сайлап алуда катнашу өчен нигез булып тора.

2.4. Җәйге профильле сменаларда бер үк баланың кабат катнашуы рөхсәт ителми.

**III. Җәйге профильле сменаларда катнашучылар исемлеген төзү**

3.1. Мәктәпләрдә кандидатларны сайлап алу процедурасының ачыклыгын тәэмин итү максатыннан конкурс комиссияләре төзелә.

3.2. Конкурс комиссиясе әгъзалары саны кимендә дүрт кеше булырга тиеш. Конкурс комиссиясе составына мәктәп директоры, аның урынбасарлары, укучыларның ата-аналары вәкилләре һәм (яисә) балигъ булган укучылар керә ала.

3.3. Конкурс комиссиясен конкурс комиссиясе әгъзалары арасыннан сайлап алынган рәис җитәкли.

3.4. Конкурс комиссиясе составы мәктәп боерыгы белән раслана.

3.5. Утырышта аның әгъзаларының кимендә ⅔ өлеше катнашса, конкурс комиссиясе карарлар кабул итәргә хокуклы.

3.6. Конкурс комиссиясе карары беркетмә (нигезләмәгә 2 нче кушымта) һәм гариза (нигезләмәгә 3 нче кушымта) белән рәсмиләштерелә, алар Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең район бүлекләренә (алга таба – район бүлекләренә) бирелә.

3.7. Район бүлекләре тарафыннан тапшырылган беркетмәләр нигезендә Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе җәйге профильле сменаларда катнашучыларның гомуми исемлеген төзи һәм аны «Ял» үзәгенә юллый.

2 нче кушымта
Казан шәһәре Башкарма
комитетының 2024 елның
1 июлендәге 2753 номерлы
карары белән расланган

**Казан шәһәре мәгариф учреждениеләре укучыларының «“Ял” шәһәр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең җәйге профильле сменаларында катнашуларына квоталар**

| № т/б | Район | Лагерь | Смена үткәрү даталары | Смена атамасы | Юнәлеш | Ата-аналарның түләү күләме (сум) | Балаларның яше | Урыннар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Вахитов | «Восток» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 164) | 21.06-08.07 | «Время своих» | Социаль-педагогик. «Время своих» – бу хәзерге балалар өчен үз илебезнең тарихына чуму, Россиянең данлыклы җиңүләре һәм күренекле кешеләре турында белү мөмкинлеге | 15 000 | 7-17 | 9 |
| 2 | Вахитов | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 02.07-19.07 | «Время чудес» | Сәнгать. «Время чудес» – җәйнең матур көннәре турында һәр бала үз куллары белән шатлык һәм онытылмас тәэсирләр тудыра ала торган урын | 15 000 | 7-11 | 5 |

| № т/б | Район | Лагерь | Смена үткәрү даталары | Смена атамасы | Юнәлеш | Ата-аналарның түләү күләме (сум) | Балаларның яше | Урыннар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 | Вахитов | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 02.07-19.07 | «Пора мечтать» | Социаль-педагогик. Смена яшүсмерләргә үз хыялларын аңларга һәм аны тормышка ашыру юлын төзергә ярдәм итәчәк | 15 000 | 12-17 | 12 |
| 4 | Вахитов | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 22.07-08.08 | «Пора открытий» | Иҗади. Смена Татарстанда фәнни-технологик үсеш елы кысаларында үткәрелә | 15 000 | 7-17 | 11 |
| 5 | Вахитов | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 22.07-08.08 | «Казан яшьләре» | Иҗади. Смена катнашучылар арасында гражданлык кыйммәтләрен үстерүгә юнәлдерелгән, аларның иҗтимагый тормышта актив катнашуын стимуллаштыра | 15 000 | 7-17 | 10 |
| 6 | Вахитов | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 10.08-27.08 | «Медиа пора» | Һөнәри юнәлештә. Смена мәгълүмат киңлегендә актив катнашырга теләгән яшь талантларга ярдәм итү һәм аларны үстерү максатында үткәрелә | 15 000 | 7-17 | 20 |
| 7 | Вахитов | «Молодежный» (Татарстан Республикасы, Биектау | 24.06-11.07 | «Время сделать ход» | Иҗади. Катлаулы мәсьәләләрне, ребусларны чишәргә һәм адым саен «пасхалкалар» | 15 000 | 7-17 | 17 |

| № т/б | Район | Лагерь | Смена үткәрү даталары | Смена атамасы | Юнәлеш | Ата-аналарның түләү күләме (сум) | Балаларның яше | Урыннар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | районы, Березовка посёлогы) | | | эзләргә яратучылар өчен смена | | | |
| 8 | Вахитов | «Молодежный» (Татарстан Республикасы, Биектау районы, Березовка посёлогы) | 16.07-02.08 | «Время приключений» | Иҗади. Сменаның һәр көне кызыклы эшләр белән тулы булачак: балалар өчен мастер-класслар, саф һавада хәрәкәтчән уеннар узачак. | 15 000 | 7-17 | 8 |
| 9 | Вахитов | «Молодежный» (Татарстан Республикасы, Биектау районы, Березовка посёлогы) | 07.08-24.08 | «Пора умелых» | Һөнәри юнәлештә. Бу мәйданчык яшьләрдә әхлакый кыйммәтләр формалаштыру, эмоциональ интеллектны үстерү һәм гаиләнең мөһимлеген аңлау һәм якыннарга ярдәм итү өчен | 15 000 | 7-17 | 9 |
| 10 | Вахитов | «Юнитур» (Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Зеленый бор поселогы) | 03.06-20.06 | «Летняя пора» | Экологик юнәлештәге смена һәм ул, барыннан да элек, төрле мәдәни, интеллектуаль, иҗади һәм спорт конкурсларында катнашу исәбенә балаларның шәхси үсешенә юнәлдерелгән. | 13 000 | 7-17 | 4 |
| 11 | Вахитов | «Юнитур» (Татарстан | 22.07-08.08 | «Время легенд» | Экологик юнәлештәге смена һәм ул, барыннан | 13 000 | 7-17 | 5 |

| № т/б | Район | Лагерь | Смена үткәрү даталары | Смена атамасы | Юнәлеш | Ата-аналарның түләү күләме (сум) | Балаларның яше | Урыннар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Республикасы, Лаеш районы, Зеленый бор поселогы) | | | да элек, төрле мәдәни, интеллектуаль, иҗади һәм спорт конкурсларында катнашу исәбенә балаларның шәхси үсешенә юнәлдерелгән. | | | |
| 12 | Идел буе | «Восток» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 164) | 21.06-08.07 | «Время своих» | Социаль-педагогик. «Время своих» – бу хәзерге балалар өчен үз илебезнең тарихына чуму, Россиянең данлыклы җиңүләре һәм күренекле кешеләре турында белү мөмкинлеге | 15 000 | 7-17 | 14 |
| 13 | Идел буе | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 02.07-19.07 | «Время чудес» | Сәнгать. «Время чудес» сменасы – җәйнең матур көннәре турында һәр бала үз куллары белән шатлык һәм онытылмас тәэсирләр тудыра ала торган урын | 15 000 | 7-11 | 7 |
| 14 | Идел буе | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 02.07-19.07 | «Пора мечтать» | Социаль-педагогик. Смена яшүсмерләргә үз хыялларын аңларга һәм аны тормышка ашыру юлын төзергә ярдәм итәчәк | 15 000 | 12-17 | 19 |

| № т/б | Район | Лагерь | Смена үткәрү даталары | Смена атамасы | Юнәлеш | Ата-аналарның түләү күләме (сум) | Балаларның яше | Урыннар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 15 | Идел буе | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 22.07-08.08 | «Пора открытий» | Иҗади. Смена Татарстанда фәнни-технологик үсеш елы кысаларында үткәрелә | 15 000 | 7-17 | 17 |
| 16 | Идел буе | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 22.07-08.08 | «Казан яшьләре» | Иҗади. Смена катнашучылар арасында гражданлык кыйммәтләрен үстерүгә юнәлдерелгән, аларның иҗтимагый тормышта актив катнашуын стимуллаштыра | 15 000 | 7-17 | 15 |
| 17 | Идел буе | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 10.08-27.08 | «Медиа пора» | Һөнәри юнәлештә. Смена мәгълүмат киңлегендә актив катнашырга теләгән яшь талантларга ярдәм итү һәм аларны үстерү максатында үткәрелә | 15 000 | 7-17 | 32 |
| 18 | Идел буе | «Молодежный» (Татарстан Республикасы, Биектау районы, Березовка посёлогы) | 24.06-11.07 | «Время сделать ход» | Иҗади. Катлаулы мәсьәләләрне, ребусларны чишәргә һәм адым саен «пасхалкалар» эзләргә яратучылар өчен смена | 15 000 | 7-17 | 27 |
| 19 | Идел буе | «Молодежный» (Татарстан Республикасы, | 16.07-02.08 | «Время приключений» | Иҗади. Сменаның һәр көне кызыклы эшләр белән | 15 000 | 7-17 | 13 |

| № т/б | Район | Лагерь | Смена үткәрү даталары | Смена атамасы | Юнәлеш | Ата-аналарның түләү күләме (сум) | Балаларның яше | Урыннар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Биектау районы, Березовка посёлогы) | | | тулы булачак: балалар өчен мастер-класслар, саф һавада хәрәкәтчән уеннар узачак. | | | |
| 20 | Идел буе | «Молодежный» (Татарстан Республикасы, Биектау районы, Березовка посёлогы) | 07.08-24.08 | «Пора умелых» | Һөнәри юнәлештә. Бу мәйданчык яшьләрдә әхлакый кыйммәтләр формалаштыру, эмоциональ интеллектны үстерү һәм гаиләнең мөһимлеген аңлау һәм якыннарга ярдәм итү өчен | 15 000 | 7-17 | 14 |
| 21 | Идел буе | «Юнитур» (Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Зеленый бор поселогы) | 03.06-20.06 | «Летняя пора» | Экологик юнәлештәге смена һәм ул, барыннан да элек, төрле мәдәни, интеллектуаль, иҗади һәм спорт конкурсларында катнашу исәбенә балаларның шәхси үсешенә юнәлдерелгән. | 13 000 | 7-17 | 6 |
| 22 | Идел буе | «Юнитур» (Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Зеленый бор поселогы) | 22.07-08.08 | «Время легенд» | Экологик юнәлештәге смена һәм ул, барыннан да элек, төрле мәдәни, интеллектуаль, иҗади һәм спорт конкурсларында катнашу исәбенә балаларның | 13 000 | 7-17 | 8 |

| № т/б | Район | Лагерь | Смена үткәрү даталары | Смена атамасы | Юнәлеш | Ата-аналарның түләү күләме (сум) | Балаларның яше | Урыннар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | шәхси үсешенә юнәлдерелгән. | | | |
| 23 | Киров | «Восток» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 164) | 21.06-08.07 | «Время своих» | Социаль-педагогик. «Время своих» – бу хәзерге балалар өчен үз илебезнең тарихына чуму, Россиянең данлыклы җиңүләре һәм күренекле кешеләре турында белү мөмкинлеге | 15 000 | 7-17 | 9 |
| 24 | Киров | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 02.07-19.07 | «Время чудес» | Сәнгать. «Время чудес» сменасы – җәйнең матур көннәре турында һәр бала үз куллары белән шатлык һәм онытылмас тәэсирләр тудыра ала торган урын | 15 000 | 7-11 | 5 |
| 25 | Киров | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 02.07-19.07 | «Пора мечтать» | Социаль-педагогик. Смена яшүсмерләргә үз хыялларын аңларга һәм аны тормышка ашыру юлын төзергә ярдәм итәчәк | 15 000 | 12-17 | 12 |
| 26 | Киров | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 22.07-08.08 | «Пора открытий» | Иҗади. Смена Татарстанда фәнни-технологик үсеш елы кысаларында үткәрелә | 15 000 | 7-17 | 11 |

| № т/б | Район | Лагерь | Смена үткәрү даталары | Смена атамасы | Юнәлеш | Ата-аналарның түләү күләме (сум) | Балаларның яше | Урыннар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 27 | Киров | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 22.07-08.08 | «Казан яшьләре» | Иҗади. Смена катнашучылар арасында гражданлык кыйммәтләрен үстерүгә юнәлдерелгән, аларның иҗтимагый тормышта актив катнашуын стимуллаштыра | 15 000 | 7-17 | 10 |
| 28 | Киров | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 10.08-27.08 | «Медиа пора» | Һөнәри юнәлештә. Смена мәгълүмат киңлегендә актив катнашырга теләгән яшь талантларга ярдәм итү һәм аларны үстерү максатында үткәрелә | 15 000 | 7-17 | 20 |
| 29 | Киров | «Молодежный» (Татарстан Республикасы, Биектау районы, Березовка посёлогы) | 24.06-11.07 | «Время сделать ход» | Иҗади. Катлаулы мәсьәләләрне, ребусларны чишәргә һәм адым саен «пасхалкалар» эзләргә яратучылар өчен смена | 15 000 | 7-17 | 17 |
| 30 | Киров | «Молодежный» (Татарстан Республикасы, Биектау районы, Березовка посёлогы) | 16.07-02.08 | «Время приключений» | Иҗади. Сменаның һәр көне кызыклы эшләр белән тулы булачак: балалар өчен мастер-класслар, саф һавада хәрәкәтчән уеннар узачак. | 15 000 | 7-17 | 8 |

| № т/б | Район | Лагерь | Смена үткәрү даталары | Смена атамасы | Юнәлеш | Ата-аналарның түләү күләме (сум) | Балаларның яше | Урыннар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 31 | Киров | «Молодежный» (Татарстан Республикасы, Биектау районы, Березовка посёлогы) | 07.08-24.08 | «Пора умелых» | Һөнәри юнәлештә. Бу мәйданчык яшьләрдә әхлакый кыйммәтләр формалаштыру, эмоциональ интеллектны үстерү һәм гаиләнең мөһимлеген аңлау һәм якыннарга ярдәм итү өчен | 15 000 | 7-17 | 9 |
| 32 | Киров | «Юнитур» (Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Зеленый бор поселогы) | 03.06-20.06 | «Летняя пора» | Экологик юнәлештәге смена һәм ул, барыннан да элек, төрле мәдәни, интеллектуаль, иҗади һәм спорт конкурсларында катнашу исәбенә балаларның шәхси үсешенә юнәлдерелгән. | 13 000 | 7-17 | 4 |
| 33 | Киров | «Юнитур» (Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Зеленый бор поселогы) | 22.07-08.08 | «Время легенд» | Экологик юнәлештәге смена һәм ул, барыннан да элек, төрле мәдәни, интеллектуаль, иҗади һәм спорт конкурсларында катнашу исәбенә балаларның шәхси үсешенә юнәлдерелгән. | 13 000 | 7-17 | 5 |
| 34 | Мәскәү | «Восток» (Казан шәһәре, Горький | 21.06-08.07 | «Время своих» | Социаль-педагогик. «Время своих» – бу хәзерге балалар өчен үз | 15 000 | 7-17 | 8 |

| № т/б | Район | Лагерь | Смена үткәрү даталары | Смена атамасы | Юнәлеш | Ата-аналарның түләү күләме (сум) | Балаларның яше | Урыннар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Шоссесы урамы, 164) | | | илебезнең тарихына чуму, Россиянең данлыклы җиңүләре һәм күренекле кешеләре турында белү мөмкинлеге | | | |
| 35 | Мәскәү | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 02.07-19.07 | «Время чудес» | Сәнгать.<br>«Время чудес» сменасы – җәйнең матур көннәре турында һәр бала үз куллары белән шатлык һәм онытылмас тәэсирләр тудыра ала торган урын | 15 000 | 7-11 | 4 |
| 36 | Мәскәү | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 02.07-19.07 | «Пора мечтать» | Социаль-педагогик.<br>Смена яшүсмерләргә үз хыялларын аңларга һәм аны тормышка ашыру юлын төзергә ярдәм итәчәк | 15 000 | 12-17 | 12 |
| 37 | Мәскәү | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 22.07-08.08 | «Пора открытий» | Иҗади.<br>Смена Татарстанда фәнни-технологик үсеш елы кысаларында үткәрелә | 15 000 | 7-17 | 10 |
| 38 | Мәскәү | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 22.07-08.08 | «Казан яшьләре» | Иҗади.<br>Смена катнашучылар арасында гражданлык кыйммәтләрен үстерүгә юнәлдерелгән, аларның | 15 000 | 7-17 | 9 |

| № т/б | Район | Лагерь | Смена үткәрү даталары | Смена атамасы | Юнәлеш | Ата-аналарның түләү күләме (сум) | Балаларның яше | Урыннар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | иҗтимагый тормышта актив катнашуын стимуллаштыра | | | |
| 39 | Мәскәү | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 10.08-27.08 | «Медиа пора» | Һөнәри юнәлештә. Смена мәгълүмат киңлегендә актив катнашырга теләгән яшь талантларга ярдәм итү һәм аларны үстерү максатында үткәрелә | 15 000 | 7-17 | 19 |
| 40 | Мәскәү | «Молодежный» (Татарстан Республикасы, Биектау районы, Березовка посёлогы) | 24.06-11.07 | «Время сделать ход» | Иҗади. Катлаулы мәсьәләләрне, ребусларны чишәргә һәм адым саен «пасхалкалар» эзләргә яратучылар өчен смена | 15 000 | 7-17 | 16 |
| 41 | Мәскәү | «Молодежный» (Татарстан Республикасы, Биектау районы, Березовка посёлогы) | 16.07-02.08 | «Время приключений» | Иҗади. Сменаның һәр көне кызыклы эшләр белән тулы булачак: балалар өчен мастер-класслар, саф һавада хәрәкәтчән уеннар узачак. | 15 000 | 7-17 | 8 |
| 42 | Мәскәү | «Молодежный» (Татарстан Республикасы, Биектау районы, | 07.08-24.08 | «Пора умелых» | Һөнәри юнәлештә. Бу мәйданчык яшьләрдә әхлакый кыйммәтләр формалаштыру, эмоциональ интеллектны үстерү һәм гаиләнең | 15 000 | 7-17 | 8 |

| № т/б | Район | Лагерь | Смена үткәрү даталары | Смена атамасы | Юнәлеш | Ата-аналарның түләү күләме (сум) | Балаларның яше | Урыннар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Березовка посёлогы) | | | мөһимлеген аңлау һәм якыннарга ярдәм итү өчен | | | |
| 43 | Мәскәү | «Юнитур» (Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Зеленый бор поселогы) | 03.06-20.06 | «Летняя пора» | Экологик юнәлештәге смена һәм ул, барыннан да элек, төрле мәдәни, интеллектуаль, иҗади һәм спорт конкурсларында катнашу исәбенә балаларның шәхси үсешенә юнәлдерелгән. | 13 000 | 7-17 | 4 |
| 44 | Мәскәү | «Юнитур» (Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Зеленый бор поселогы) | 22.07-08.08 | «Время легенд» | Экологик юнәлештәге смена һәм ул, барыннан да элек, төрле мәдәни, интеллектуаль, иҗади һәм спорт конкурсларында катнашу исәбенә балаларның шәхси үсешенә юнәлдерелгән. | 13 000 | 7-17 | 5 |
| 45 | Авиатөзелеш | «Восток» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 164) | 21.06-08.07 | «Время своих» | Социаль-педагогик. «Время своих» – бу хәзерге балалар өчен үз илебезнең тарихына чуму, Россиянең данлыклы җиңүләре һәм күренекле кешеләре турында белү мөмкинлеге | 15 000 | 7-17 | 8 |

| № т/б | Район | Лагерь | Смена үткәрү даталары | Смена атамасы | Юнәлеш | Ата-аналарның түләү күләме (сум) | Балаларның яше | Урыннар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 46 | Авиатөзелеш | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 02.07-19.07 | «Время чудес» | Сәнгать.<br>«Время чудес» сменасы – җәйнең матур көннәре турында һәр бала үз куллары белән шатлык һәм онытылмас тәэсирләр тудыра ала торган урын | 15 000 | 7-11 | 4 |
| 47 | Авиатөзелеш | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 02.07-19.07 | «Пора мечтать» | Социаль-педагогик.<br>Смена яшүсмерләргә үз хыялларын аңларга һәм аны тормышка ашыру юлын төзергә ярдәм итәчәк | 15 000 | 12-17 | 12 |
| 48 | Авиатөзелеш | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 22.07-08.08 | «Пора открытий» | Иҗади.<br>Смена Татарстанда фәнни-технологик үсеш елы кысаларында үткәрелә | 15 000 | 7-17 | 10 |
| 49 | Авиатөзелеш | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 22.07-08.08 | «Казан яшьләре» | Иҗади.<br>Смена катнашучылар арасында гражданлык кыйммәтләрен үстерүгә юнәлдерелгән, аларның иҗтимагый тормышта актив катнашуын стимуллаштыра | 15 000 | 7-17 | 9 |
| 50 | Авиатөзелеш | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький | 10.08-27.08 | «Медиа пора» | Һөнәри юнәлештә.<br>Смена мәгълүмат киңлегендә актив | 15 000 | 7-17 | 20 |

| № т/б | Район | Лагерь | Смена үткәрү даталары | Смена атамасы | Юнәлеш | Ата-аналарның түләү күләме (сум) | Балаларның яше | Урыннар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Шоссесы урамы, 103) | | | катнашырга теләгән яшь талантларга ярдәм итү һәм аларны үстерү максатында үткәрелә | | | |
| 51 | Авиатөзелеш | «Молодежный» (Татарстан Республикасы, Биектау районы, Березовка посёлогы) | 24.06-11.07 | «Время сделать ход» | Иҗади.<br>Катлаулы мәсьәләләрне, ребусларны чишәргә һәм адым саен «пасхалкалар» эзләргә яратучылар өчен смена | 15 000 | 7-17 | 16 |
| 52 | Авиатөзелеш | «Молодежный» (Татарстан Республикасы, Биектау районы, Березовка посёлогы) | 16.07-02.08 | «Время приключений» | Иҗади.<br>Сменаның һәр көне кызыклы эшләр белән тулы булачак: балалар өчен мастер-класслар, саф һавада хәрәкәтчән уеннар узачак. | 15 000 | 7-17 | 7 |
| 53 | Авиатөзелеш | «Молодежный» (Татарстан Республикасы, Биектау районы, Березовка посёлогы) | 07.08-24.08 | «Пора умелых» | Һөнәри юнәлештә.<br>Бу мәйданчык яшьләрдә әхлакый кыйммәтләр формалаштыру, эмоциональ интеллектны үстерү һәм гаиләнең мөһимлеген аңлау һәм якыннарга ярдәм итү өчен | 15 000 | 7-17 | 8 |
| 54 | Авиатөзелеш | «Юнитур» (Татарстан Республикасы, | 03.06-20.06 | «Летняя пора» | Экологик юнәлештәге смена һәм ул, барыннан да элек, төрле мәдәни, | 13 000 | 7-17 | 4 |

| № т/б | Район | Лагерь | Смена үткәрү даталары | Смена атамасы | Юнәлеш | Ата-аналарның түләү күләме (сум) | Балаларның яше | Урыннар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Лаеш районы, Зеленый бор поселогы) | | | интеллектуаль, иҗади һәм спорт конкурсларында катнашу исәбенә балаларның шәхси үсешенә юнәлдерелгән. | | | |
| 55 | Авиатөзелеш | «Юнитур» (Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Зеленый бор поселогы) | 22.07-08.08 | «Время легенд» | Экологик юнәлештәге смена һәм ул, барыннан да элек, төрле мәдәни, интеллектуаль, иҗади һәм спорт конкурсларында катнашу исәбенә балаларның шәхси үсешенә юнәлдерелгән. | 13 000 | 7-17 | 5 |
| 56 | Яңа Савин | «Восток» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 164) | 21.06-08.07 | «Время своих» | Социаль-педагогик. «Время своих» – бу хәзерге балалар өчен үз илебезнең тарихына чуму, Россиянең данлыклы җиңүләре һәм күренекле кешеләре турында белү мөмкинлеге | 15 000 | 7-17 | 12 |
| 57 | Яңа Савин | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 02.07-19.07 | «Время чудес» | Сәнгать. «Время чудес» сменасы – җәйнең матур көннәре турында һәр бала үз куллары белән шатлык һәм онытылмас | 15 000 | 7-11 | 6 |

| № т/б | Район | Лагерь | Смена үткәрү даталары | Смена атамасы | Юнәлеш | Ата-аналарның түләү күләме (сум) | Балаларның яше | Урыннар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | тәэсирләр тудыра ала торган урын | | | |
| 58 | Яңа Савин | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 02.07-19.07 | «Пора мечтать» | Социаль-педагогик. Смена яшүсмерләргә үз хыялларын аңларга һәм аны тормышка ашыру юлын төзергә ярдәм итәчәк | 15 000 | 12-17 | 16 |
| 59 | Яңа Савин | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 22.07-08.08 | «Пора открытий» | Иҗади. Смена Татарстанда фәнни-технологик үсеш елы кысаларында үткәрелә | 15 000 | 7-17 | 14 |
| 60 | Яңа Савин | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 22.07-08.08 | «Казан яшьләре» | Иҗади. Смена катнашучылар арасында гражданлык кыйммәтләрен үстерүгә юнәлдерелгән, аларның иҗтимагый тормышта актив катнашуын стимуллаштыра | 15 000 | 7-17 | 15 |
| 61 | Яңа Савин | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 10.08-27.08 | «Медиа пора» | Һөнәри юнәлештә. Смена мәгълүмат киңлегендә актив катнашырга теләгән яшь талантларга ярдәм итү һәм аларны үстерү максатында үткәрелә | 15 000 | 7-17 | 27 |
| 62 | Яңа Савин | «Молодежный» (Татарстан | 24.06-11.07 | «Время сделать ход» | Иҗади. | 15 000 | 7-17 | 23 |

| № т/б | Район | Лагерь | Смена үткәрү даталары | Смена атамасы | Юнәлеш | Ата-аналарның түләү күләме (сум) | Балаларның яше | Урыннар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Республикасы, Биектау районы, Березовка посёлогы) | | | Катлаулы мәсьәләләрне, ребусларны чишәргә һәм адым саен «пасхалкалар» эзләргә яратучылар өчен смена | | | |
| 63 | Яңа Савин | «Молодежный» (Татарстан Республикасы, Биектау районы, Березовка посёлогы) | 16.07-02.08 | «Время приключений» | Иҗади.<br>Сменаның һәр көне кызыклы эшләр белән тулы булачак: балалар өчен мастер-класслар, саф һавада хәрәкәтчән уеннар узачак. | 15 000 | 7-17 | 11 |
| 64 | Яңа Савин | «Молодежный» (Татарстан Республикасы, Биектау районы, Березовка посёлогы) | 07.08-24.08 | «Пора умелых» | Һөнәри юнәлештә.<br>Бу мәйданчык яшьләрдә әхлакый кыйммәтләр формалаштыру, эмоциональ интеллектны үстерү һәм гаиләнең мөһимлеген аңлау һәм якыннарга ярдәм итү өчен | 15 000 | 7-17 | 12 |
| 65 | Яңа Савин | «Юнитур» (Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Зеленый бор поселогы) | 03.06-20.06 | «Летняя пора» | Экологик юнәлештәге смена һәм ул, барыннан да элек, төрле мәдәни, интеллектуаль, иҗади һәм спорт конкурсларында катнашу исәбенә балаларның шәхси үсешенә юнәлдерелгән. | 13 000 | 7-17 | 5 |

| № т/б | Район | Лагерь | Смена үткәрү даталары | Смена атамасы | Юнәлеш | Ата-аналарның түләү күләме (сум) | Балаларның яше | Урыннар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 66 | Яңа Савин | «Юнитур» (Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Зеленый бор поселогы) | 22.07-08.08 | «Время легенд» | Экологик юнәлештәге смена һәм ул, барыннан да элек, төрле мәдәни, интеллектуаль, иҗади һәм спорт конкурсларында катнашу исәбенә балаларның шәхси үсешенә юнәлдерелгән. | 13 000 | 7-17 | 7 |
| 67 | Совет | «Восток» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 164) | 21.06-08.07 | «Время своих» | Социаль-педагогик. «Время своих» – бу хәзерге балалар өчен үз илебезнең тарихына чуму, Россиянең данлыклы җиңүләре һәм күренекле кешеләре турында белү мөмкинлеге | 15 000 | 7-17 | 19 |
| 68 | Совет | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 02.07-19.07 | «Время чудес» | Сәнгать. «Время чудес» сменасы – җәйнең матур көннәре турында һәр бала үз куллары белән шатлык һәм онытылмас тәэсирләр тудыра ала торган урын | 15 000 | 7-11 | 9 |
| 69 | Совет | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький | 02.07-19.07 | «Пора мечтать» | Социаль-педагогик. Смена яшүсмерләргә үз хыялларын аңларга һәм аны тормышка ашыру | 15 000 | 12-17 | 25 |

| № т/б | Район | Лагерь | Смена үткәрү даталары | Смена атамасы | Юнәлеш | Ата-аналарның түләү күләме (сум) | Балаларның яше | Урыннар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Шоссесы урамы, 103) | | | юлын төзергә ярдәм итәчәк | | | |
| 70 | Совет | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 22.07-08.08 | «Пора открытий» | Иҗади. Смена Татарстанда фәнни-технологик үсеш елы кысаларында үткәрелә | 15 000 | 7-17 | 23 |
| 71 | Совет | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 22.07-08.08 | «Казан яшьләре» | Иҗади. Смена катнашучылар арасында гражданлык кыйммәтләрен үстерүгә юнәлдерелгән, аларның иҗтимагый тормышта актив катнашуын стимуллаштыра | 15 000 | 7-17 | 21 |
| 72 | Совет | «Заречье» (Казан шәһәре, Горький Шоссесы урамы, 103) | 10.08-27.08 | «Медиа пора» | Һөнәри юнәлештә. Смена мәгълүмат киңлегендә актив катнашырга теләгән яшь талантларга ярдәм итү һәм аларны үстерү максатында үткәрелә | 15 000 | 7-17 | 43 |
| 73 | Совет | «Молодежный» (Татарстан Республикасы, Биектау районы, Березовка посёлогы) | 24.06-11.07 | «Время сделать ход» | Иҗади. Катлаулы мәсьәләләрне, ребусларны чишәргә һәм адым саен «пасхалкалар» эзләргә яратучылар өчен смена | 15 000 | 7-17 | 35 |

| № т/б | Район | Лагерь | Смена үткәрү даталары | Смена атамасы | Юнәлеш | Ата-аналарның түләү күләме (сум) | Балаларның яше | Урыннар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 74 | Совет | «Молодежный» (Татарстан Республикасы, Биектау районы, Березовка посёлогы) | 16.07-02.08 | «Время приключений» | Иҗади. Сменаның һәр көне кызыклы эшләр белән тулы булачак: балалар өчен мастер-класслар, саф һавада хәрәкәтчән уеннар узачак. | 15 000 | 7-17 | 17 |
| 75 | Совет | «Молодежный» (Татарстан Республикасы, Биектау районы, Березовка посёлогы) | 07.08-24.08 | «Пора умелых» | Һөнәри юнәлештә. Бу мәйданчык яшьләрдә әхлакый кыйммәтләр формалаштыру, эмоциональ интеллектны үстерү һәм гаиләнең мөһимлеген аңлау һәм якыннарга ярдәм итү өчен | 15 000 | 7-17 | 18 |
| 76 | Совет | «Юнитур» (Татарстан Республикасы, Лаеш районы, Зеленый бор поселогы) | 03.06-20.06 | «Летняя пора» | Экологик юнәлештәге смена һәм ул, барыннан да элек, төрле мәдәни, интеллектуаль, иҗади һәм спорт конкурсларында катнашу исәбенә балаларның шәхси үсешенә юнәлдерелгән. | 13 000 | 7-17 | 9 |
| 77 | Совет | «Юнитур» (Татарстан Республикасы, Лаеш районы, | 22.07-08.08 | «Время легенд» | Экологик юнәлештәге смена һәм ул, барыннан да элек, төрле мәдәни, интеллектуаль, иҗади һәм спорт | 13 000 | 7-17 | 10 |

| № т/б | Район | Лагерь | Смена үткәрү даталары | Смена атамасы | Юнәлеш | Ата-аналарның түләү күләме (сум) | Балаларның яше | Урыннар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Зеленый бор поселогы) | | | конкурсларында катнашу исәбенә балаларның шәхси үсешенә юнәлдерелгән. | | | |

«“Ял” шәһәр үзәге»
муниципаль бюджет
учреждениесенең җәйге
профильле сменаларында
катнашу өчен
кандидатларны сайлап
алу тәртибе турында
нигезләмәгә
1 нче кушымта

**«“Ял” шәһәр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең җәйге профильле сменаларында катнашу өчен укучыларны сайлап алу критерийлары**

| № т/б | Сайлап алу критерийлары | Күрсәткечләр | Баллар саны | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | чарада җиңгән өчен | призлы урын өчен | чарада катнашкан өчен |
| 1 | Кандидатның олимпиадаларда, конкурсларда, фестивальләрдә, смотрларда, конференцияләрдә һәм башка конкурс чараларында катнашу нәтиҗәлелеге | Муниципаль дәрәҗә чаралар | | | |
| | | - урында катнашу | 3 балл | 2 балл | 1 балл |
| | | - дистанцион катнашу | 2 балл | 1 балл | 1 балл |
| | | Төбәк (төбәкара) дәрәҗәдә чара | | | |
| | | - урында катнашу | 5 балл | 4 балл | 3 балл |
| | | - дистанцион катнашу | 4 балл | 3 балл | 2 балл |
| | | Россиякүләм дәрәҗәдә чара | | | |
| | | - урында катнашу | 8 балл | 7 балл | 6 балл |
| | | - дистанцион катнашу | 3 балл | 2 балл | 1 балл |
| | | Халыкара дәрәҗәдә чара | | | |
| | | - урында катнашу | 9 балл | 6 балл | 4 балл |
| | | - дистанцион катнашу | 3 балл | 2 балл | 1 балл |
| 2 | Иҗат коллективлары, спорт командалары составында олимпиадаларда, конкурсларда, фестивальләрдә, смотрларда, | Муниципаль, төбәк (төбәкара), россиякүләм һәм халыкара дәрәҗәдә чаралар | 3 балл | 2 балл | 1 балл |

| № т/б | Сайлап алу критерийлары | Күрсәткечләр | Баллар саны | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | чарада җиңгән өчен | призлы урын өчен | чарада катнашкан өчен |
| | конференцияләрдә һәм башка конкурс чараларында кандидатның катнашу нәтиҗәлелеге (урында катнашу) | | | | |
| 3 | Кандидатларның казанышларын тану | Бүләкләр булу (грамоталар, рәхмәт хатлары) | 1 бүләк – 1 балл | | |
| 4 | Кандидатның социаль активлыгы дәрәҗәсе (социаль проектларда, социаль әһәмияткә ия чараларда, акцияләрдә, проектларда, волонтерлык хәрәкәтендә катнашу) | Бүләкләр булу (грамоталар, рәхмәт хатлары) | 1 бүләк – 1 балл | | |
| 5 | Өлгереш | Уртача өлгереш баллы | | | |
| 6 | **БАРЛЫГЫ** | | | | |

*Искәрмә: барлык критерийлар да өч уку елы өчен карала (2021 елның 1 сентябреннән).

«“Ял” шәһәр үзәге»
муниципаль бюджет
учреждениесенең җәйге
профильле сменаларында
катнашу өчен кандидатларны
сайлап алу тәртибе турында
нигезләмәгә
2 нче кушымта

**«“Ял” шәһәр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең җәйге профильле сменаларында катнашу өчен кандидатларны сайлап алу беркетмәсе**

___________________________________________________________

(учреждение атамасы)

Катнаштылар:

Чакыру кәгазе:

Карар:

| № т/б | Фамилия, исем, атасы исеме | Сыйныф | Баллар саны | Урын |
|---|---|---|---|---|

Учреждение җитәкчесе ___________/ ___________________________
М.У.

«“Ял” шәһәр үзәге»
муниципаль бюджет
учреждениесенең җәйге
профильле сменаларында
катнашу өчен кандидатларны
сайлап алу тәртибе турында
нигезләмәгә
3 нче кушымта

**Мәгариф учреждениеләреннән кандидатларны конкурста сайлап алуда катнашуга гариза-тәкъдимнамә**

| № т/б | Укучының фамилиясе, исеме, атасы исеме | Туу датасы | Сыйныф | Укучының элемтә өчен телефоны | Ата-аналарының (законлы вәкилләрнең) фамилияләре, исемнәре, аталары исемнәре | Ата-аналарының (законлы вәкилләрнең) элемтә өчен телефоннары | Өй адресы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|